СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕ СОВЕТЫ

Решение

КАРАР

05 май 2023ел

№92

2022 елга Илмәт авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны раслау турында

Илмәт авыл жирлеге рәисе Мингалеева Р. Т. ның Илмәт авыл җирлегенең 2022 елгы бюджеты үтәлеше турындагы мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып, һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 153, 264.6 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Илмәт авыл жирлеге Советы

Карар кабул итте:

1. Илмәт авыл жирлеге бюджетының 2022 елда 3 210,2 мең сумлык керемнәр, 3 242,5 мең сумлык чыгымнар, 32,3 мең сумлык керемнәрдән артык чыгымнар һәм түбәндәге күрсәткечләр буенча үтәлеше турында хисап раслансын:

- әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бюджет керемнәрен классификацияләү кодлары буенча җирлек бюджеты керемнәре;

- әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә җирлек бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча җирлек бюджеты чыгымнары;

- әлеге карарның 3 нче кушымтасына ярашлы рәвештә, җирлек бюджеты чыгымнарының бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм бюджет чыгымнары төрләре төркемнәре буенча чыгымнары;

- максатчан статьялар (муниципаль программалар һәм программалы булмаган эшчәнлек юнәлешләре), чыгым төрләре төркемнәре, бүлекләр, бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекчәләре буенча әлеге карарга 4 нче кушымта буенча җирлек бюджеты чыгымнары;

- әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә бюджет дефицитын финанслау чыганакларын классификацияләү кодлары буенча җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганаклары;

- әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә жирлек бюджетыннан бюджетара трансфертларны бүлү буенча;

- 2022 елда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетыннан жирлек бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертларны бүлеп бирү буенча әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

Рәисе Р.Т. Мингалеева